Республика Татарстан
Глава Монашевского сельского поселения
Менделеевского муниципального района
423643, Менделеевский район, с. Монашево,
ул. Школьная, д 19

Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районы
Монашево авыл җирлеге Башлыгы

423643, Менделеевск районы,
Монашево авылы,
Мәктәп урамы, 19

тел./факс 8/85549/3-56-29, E-mail: Mon.Men@tatar.ru, http://mendeleevsk.tatarstan.ru/rus/monashevskoe-selskoe-poselenie.htm

---

ПОСТАНОВЛЕНИЕ　　　　　　　　　　КАРАР

20.11.2023 ел　　　　　　　　　　№ 5

Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Менделеевск муниципаль районы Монашево авыл җирлегенең Татар Кокшаны авылында гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы « Монашево авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 22 статьясы нигезендә,

КАРАР БИРӘМ:

1. 2023 елның 30 ноябре 11.00 сәг. Монашево авыл җирлегенең Татар Кокшаны авылында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану буенча гражданнар җыенын билгеләргә

2 Җыенны уздыру урыны итеп Татар Кокшаны Тынычлык урамы 19 йорт адресы буенча урнашкан мәчетне билгеләргә.

3. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

« «2024 елда үзара салым акчаларын Менделеевск муниципаль районының Монашево авыл җирлегенең Татар Кокшаны авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә, югары һәм урта уку йортларында көндезге бүлектә укучы студентлардан, 1 -2 төркем инвалидлардан, махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаиләләреннән тыш, ә карамагында балигъ булмаган күп балалы гаиләләрдән 500 сум күләмендә

билгеләргә  һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә сез ризамы:

1. Кокшанка елгасының үзәнен үзгәртү.

«РИЗА» «КАРШЫ»

4. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында, Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында - www.mendeleevsk.tatar.ru « Монашево авыл җирлеге» бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ru  урнаштырырга.

5. Әлеге карар кабул ителгән көннән үз көченә керә

Монашево авыл җирлеге башлыгы Р.Ф. Иосифов